РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Масягутовского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Дружба, д. 12, Азнакаевский район,
с.Масягутово, 423321,
тел./факс (885592)38-2-16
E-mail: Msg.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Мәсгут авыл җирлеге
башлыгы

Дружба ур., 12 йорт, Азнакай районы,
Мәсгут авылы, 423321
тел./факс (885592)38-2-16
E-mail: Msg.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«29»апреля 2022ел..** **№ 2**

Азнакай муниципаль районы « Мәсгут авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш
кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча
ачык тыңлаулар билгеләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31нче маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль берәмлеге « Мәсгут авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Азнакай муниципаль районы авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл Мәсгут җирлеге Советының 2014-елның 22 гыйнварыннан 23 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Мәсгут авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча ачык тыңлаулар билгеләргә 09.12.2016 № 38, 04.09.2017 №55, 02.07.2018 № 93, 08.04.2019 № 120, 18.02.2020 № 153, 28.04.2021 №8 карарлар редакциясендә)

2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү буенча ачык тыңлауларны оештыручы комиссияне;
- үткәрү вакыты - 2022 елның 04 маеннан 2022 елның 01 июненә кадәр 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны – Мәсгут авылы, Г.Багманова урамы, 16 йорт;
- тикшерелә торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр

кертелергә мөмкин булган адрес – Мәсгут авылы, Дружба урамы, 12 йорт,Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге башкарма комитеты.

4. Азнакай муниципаль районы авыл җирлегенец җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенә тәкъдим итәргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Мәсгут авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда ачык тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Мәсгут авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән куллану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектын Интернет мәгълүмат-/телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru/.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http//aznakayevo.tatar.ru/.

6. Әлеге карарнщ үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Д.З.Миннеханов